Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл җирлегенең
Рус Акташы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы
карары

19 ноябрь 2021 ел №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2021 елның 08 ноябре 16 сәгать 00 минутта, 2021 елның 09 ноябре 17 сәгать 00 минутта,2021 елның 10 ноябре 17 сәгать 00 минутта,2021 елның 11» ноябре 17 сәгать 00 минутта,2021 елның 12 ноябре 17сәгать 00 минутта,2021 елның 12 ноябре 17 сәгать 00 минутта,2021 елның 13 ноябре 14 сәгать 00 минутта,2021 елның 16 ноябре 17 сәгать 00 минутта, 2021 елның 17 ноябре 17 сәгать 00 минутта, 2021 елның 18 ноябре 17 сәгать 00 минутта, узган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендә«Сез 2022 елда үзара салым кертүгә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Рус Акташы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: юлларны, су белән тәэмин итү системаларын норматив хәлгә китерү (бораулау), сметалар төзү өчен түләү,техник күзәтү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү?»сораулары буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 2979 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 1524 кеше, бу 51,1 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 1534-е«РИЗА»позициясе өчен тавыш бирде; гражданнар җыенында катнашучыларның 140-ы«КАРШЫ»позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карарбирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл җирлегенең Рус Акташы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл җирлегенең Рус Акташы авылында яшәү урыны буенча теркәлгәнһәр балигъ булган яшәүчедән үзара салым средстволарын 2022 елда 500 сум күләмендә кертергә.

3. Җыелган үзара салым средстволарын җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрнебашкаруга юнәлдерергә:юлларны, су белән тәэмин итү системаларын норматив хәлгә китерү (бораулау), сметалар төзү өчен түләү,техник күзәтү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү.

4.Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетысында бастырырга,Рус Акташы, Төзүчеләр ур., 14өйтерриториясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә,«Татарстан Республикасының хокукый

мәгълүматларрәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайты«Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрынакертүөченҗи бәрергә.

Гражданнар җыенында рәислекитүче С.А. Белоногов